Кукмара муниципаль районы
Зур Кукмара авыл җирлеге Советы

# ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районыныщ Зур Кукмара авылы территориясенең бер елешендә 2024 елда гражданнарныц узара салымын керту турында

2023 елның 24 ноябре, №32

«Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле узидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә Зур Кукмара авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, 1 төркем инвалидлары, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәкләрдән тыш, 2024 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Зур Кукмара авылы территориясенең Урман урамы чикләрендәге бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгэә балигъ булган һәр кешедән 10 500 сум күләмендә узара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлтергә:

1. Зур Кукмара авылының Урман урамын асфальтлау, экспертиза ясау, проект-смета документациясен эшләү һәм техник кузәтчелекне тормышка ашыру.

3. Әлеге карарны Зур Кукмара авыл җирлегенең магълүмат стендларында Татарстан Республикасы хокукый магълуматының рәсми порталында pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, шулай ук «Интернет» магълүмати-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районыныщ рәсми сайтында кабул ителгән көннэн алып 5 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар жыенында рәислек итүче,
Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара
авыл жирлеге башлыгы Р Р. Ханафиев.